| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАЙРЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ул.Ютазинская, д.14А,<br>с.Байряка, 423963 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>Ютазы урамы, 14А йорты,<br>Бәйрәкә авылы, 423963 |

Тел.:(85593) 2-44-11, факс:2-44-13, e-mail: Bay.Utz@tatar.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№6 «08» февраль 2022 года

Бәйрәкә авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 24 мартындагы «Җирле референдум турында»гы 23-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

2021 елның 20 декабрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктында халык җыенының 13 санлы карарларын гамәлгә ашыру максатларында,

Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Бәйрәкә авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчасын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында, (http:pravo.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы А.О.Әхмәтшина

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ * ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ * СОВЕТ БАЙРЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Бәйрәкә авыл җирлегенең
2022 елның 8 февраль
6 санлы
карарына 1 кушымта

Бәйрәкә авыл җирлеге
гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

1. Әлеге тәртип Бәйрәкә авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Бәйрәкә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яше тулган гражданнар, тавыш бирүдә катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, 2022 елның 17 гыйнварыннан 2022 елның 20 мартына кадәр үзара салым акчалары түләү башкарыла.

3. Җитди сәбәпләр булган очракта, ә аларга түбәндәгеләр керә ала:

а) торган урын буенча озак яшәмәү,

б) авыру,

гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан да артмаган вакытка кичектерергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (искәртү) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук имзаны тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (искәртүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Димтамак авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр акчаны физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша, Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша күчерелә.

7. Түләү фактын раслый торган касса ордерының квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салымы акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Бәйрәкә авыл җирлегенең 2022
елның 8 февраль
6 санлы карарына 2 кушымта

Бәйрәкәк авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
№ __________________ санлы ХӘБӘРНАМӘ (ИСКӘРТҮ)

Түләүченең Ф.И.А.
______________________________________________________

Адрес:
__________________________________________________________________

Халык җыены карары нигезендә торак пунктта_____________________Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге 2022 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча сезгә __________ _ _ _ _ кадәр халык җыены чараларын тормышка ашыру өчен бер тапкыр түләүне түбәндәге реквизитлар буенча башкарырга кирәк:

Банк получателя
БИК

Алучы
Счет номеры №
ИНН КПП
КБК
ОКТМО
Билгеләнгән түләү **2022 ел өчен гражданнарның үзара салым акчасы.**

Җитәкче
____________________________________________________________
П.У. (имза)
(имзаны раслау)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү линиясе** - - - - - - - - - - - - - - -

Димтамак авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
№ __________________ санлы хәбәрнамә (искәртү)
(*муниципаль берәмлек исеме)*
________________ сум күләмендә
Түләүченең Ф.И.А.
______________________________________________________

Адрес:

_____________________________________________________________________

«__» ________________ 20__ елны ____________________________________ алдым

(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Бәйрәкә авыл җирлеге Башкарма комитетында, мәгълүмат түләүчегә шәхси тапшырылган очракта, аерым корешок тутырыла һәм кала.*